**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**01 октябрь 2022 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның11 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 теркем инвалидлар,80 яшьтән елкәнерәк пенсионерлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Балтач авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләннәрен чабу;
- Трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Трактор ечен җиһазлар сатып алу;
- Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу, чүп-чар җыю;
- Балтач авылы юлларын төзекләндерү;
- Янгынга каршы эшчәнлек, янгын инвентаре сатып алу

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 346 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 201.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе ечен 201 , «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дерес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар,80 яшьтән өлкәнерәк пенсионерлар ечен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү

һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы

- Урам яктырткычлары, яктырткычлар ,махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру
-- Балтач авылында килешү буенча эшләр ечен түләү;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләннәрен чабу;
- Балтач авылы зираты территориясендә чүп уләннәрен чабу
- Балтач авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү,
"Җиңү Кене « Сабантуй», « Өлкәннәр көне»,» Яңа ел"
- Трактор ечен ягулык-майлау материаллары сатып алу
- Трактор өчен җиһазлар сатып алу ( төягеч, чапкыч)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Балтач авыл җирлөге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге башлыгы

(имза)

Л.Л.Хабипов
(имза расшифровкасы